| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА КУРАЛОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>КУРАЛОВО АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.11.2021 02

с. Куралово

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегенең Рус Борнашы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 нче елның 6 нчы декабрендә 11 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Рус Борнашы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2021 нче елның 6 нчы декабрендә 13 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Рус Борнашы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Халык исемлеген бүлү территориаль билге буенча башкарыла.

1 этап: Рус Борнашы авылы,Цветочная ур., Кече ур., Зур,

2 этап: Рус Борнашы авылы, Совет ур., Ерак ур., Заречная ур.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2021 нче елда Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге Рус Борнашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- Рус Борнашы авылында гамәлдәге юлга вак таш салу

«ӘЙЕ» «ЮК»

5. Халык җыеннары үткәрергә:

1 этап: Рус Борнашы авылының Зур урамы буенча 4-нче номерлы йорт янында

2 этап: Рус Борнашы авылының Заречная урамы буенча 1-нче номерлы йорт янында

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге башлыгы В.Г.Квашнев